# ЯЗМЫШЛАР

*Туунын мәгънәсе нәрсәдә? Үлемнең мәгънәсе нәрсәдә? Җир нигә әйләнә, ник моңсу бу Җирдә, әйтсәнә? Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә? Китүнең мәгънәсе нәрсәдә? Сәбәпләре бар мәллә, сәбәпләре юк мәллә? Сөер бит барысы да, сөер бит мәгънәсе дә.*

**Заһид МӘХМҮДИ.**

16+

Айга ике тапкыр чыга

№ 7 (253)
1-16 АПРЕЛЬ
2023

Татарстан почтасы каталогындагы индексы - П 2687

## Бу санда укыгыз:

## Ходай үзе юлларыбызны шулай итеп аергандыр?!.



(4-5 нче битләрдә)


## Язмышның төсе нинди?

...Төсләр гел үзгәреп тора. Күз кем өчендер сары, кем өчендер - кара, кемгәдер - кызыл, кемгәдер - күрән.

Төсләр гел уйнап тора. Язмыш кебек. Язмышның төсе нинди? Мәхәббәтнең төсен әйтергә кем батырчылык итә? Нәфрәт нинди төстә? Балачак төсе нинди?..

(8-9 нчы битләрдә)

## Күрәчәктән качып буламы?



(10-11 нче битләрдә)

podpiska.pochta.ru

## Ил-көн яңалыклары

### Махсус хәрби операциядә һәлак булучыларның хатыннары өчен - вузларда бушлай укыту



Дәүләт Думасының Мәгърифәт комитеты башлыгы беренче урынбасары Яна Лантратова Россия Хөкүмәте башлыгы Михаил Мишустиннан махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның хатыннары өчен өстәмә ярдәм чаралары кертүне сораган. Ул институтларда бюджет бүлегендә белем алу өчен аерым квота кертергә, шулай ук, керемгә бәйсез рәвештә, социаль контракт төзү мөмкинлеген күздә тотарга тәкъдим иткән.

Лантратова аңлатып үткәнчә, хәрби хезмәткәрләрнең тол хатыннарына дәүләт ягыннан аерым игътибар кирәк. Тормышта авыр хәлдә калган бер мәлдә аларның киләчәктәге язмышы тамырдан үзгәрде, дип билгеләп үткән парламентчы.

Парламентчы сүзләренә караганда, мондый хатын-кызларның бер өлеше эшкә урнашуда кыенлыклар алдында калган. Бу исә гаилә кереме кимүгә, гомумән, тормышлары начараюга китергән. Шул сәбәпле, депутат тол хатыннарны һәм аларның балаларын социаль адаптацияләүгә юнәлдерелгән 3 закон кертүне тәкъдим иткән.

Беренче тәкъдим - бюджет хисабына вузларда бакалавриат һәм специалитет программалары буенча белем алуга аерым квота билгеләү, шулай ук өстенлекле нигездә урта һөнәри белем алу мөмкинлеге күздә тоту.

Лантратова шулай ук Министрлар Кабинетына һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең хатыннарына, керемнәренә бәйсез рәвештә, социаль контракт төзү мөмкинлеге бирүне тәкъдим иткән. Бу тәкъдим хатын-кызларга бизнесны башлап җибәрүгә ярдәм итү хезмәтләреннән (бизнес-инкубатор хезмәтләре) ташламалы шартларда файдалану мөмкинлеген ача.

*("Татар-информ")*

## Газеталарга 2023 елның икенче ярты еллыгына язылу башланды!

ПОЧТА РОССИИ

ПОЧТА РОССИИ

** Яртыеллыкка, ягъни алты айга, газеталарыбызга язылу бәяләре түбәндәгечә:**

**"СЕБЕРКЕ"**

Татарстан буенча - 811 сум;

Регионнар буенча - 1002 сумнан алып.

**"СЕРЕМНЕ СИҢА ЧИШӘМ"**

Татарстан буенча - 726 сум;

Регионнар буенча - 882 сумнан алып.

**"ЯЗМЫШЛАР"**

Татарстан буенча - 545 сум;

Регионнар буенча - 642 сумнан алып.

**"ПЕНСИОНЕР ГАЗЕТАСЫ"**

Татарстан буенча - 299 сум;

Регионнар буенча - 366 сумнан алып.

**"КҮРКӘМ ХАТЫН", "ГАЙБӘТЧЕ", "БЕРГЕНӘМ-БЕРДӘНБЕРЕМ"**

Татарстан буенча - 332 сум;

Регионнар буенча - 402 сумнан алып.

**"МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ"**

Татарстан буенча - 506 сум.

* * * * * * * * * * * * * * * * * * * * * * *

**"Себерке"** - айга 4 тапкыр, 32 битле булып, атналык телепрограмма белән чыга. **Индексы - П 2496.**

**"Серемне сиңа чишәм"** - айга 4 тапкыр чыга, **индексы - П 2505.**

**"Язмышлар"** - айга 2 тапкыр чыга, **индексы - П 2687.**

**"Пенсионер газетасы", индексы - П 5248.**

**"Күркәм хатын", индексы - П 5249.**

**"Гайбәтче", индексы - П 5251.**

**"Бергенәм-бердәнберем", индексы - П 5250.**

**"Мәхәббәт һәм нәфрәт" - Индексы - ПА909.**

podpiska.pochta.ru

# Яңа тормыш башларгамы?



...Казанда югары уку йортын тәмамлагач, мине Татарстаның көнчыгышында урнашкан бер шәһәргә эшкә җибәрделәр. Ул елларда безнең башлар кадерле иде - яшь белгеч дип күтәреп алдылар, барлык уңайлы шартлар тудырдылар. Яшәп торырга фатирга керттеләр. Бер ел да узмастан, үземнең хезмәттәш кызга өйләнеп тә куйдым. Сөеклем читтән торып укырга керде, бала туу да комачаулык итмәде, хатыным дипломлы белгеч булды. Яшь гаилә дип, озакламый үзебезгә фатир бирделәр. Ул чактагы шатланулар!

Менә шулай матур гына яшәп ятканда, хатыным бер танышының сүзен кире какмыйм дип, аның ерак кына туган тиешле сеңлесен үзебезгә фатирга кертергә уйлады. Әлфияне дә безнең шәһәргә юллама белән эшкә җибәргәннәр икән. Беркеме булмаган урында авырдыр, терәк булырбыз, диде хатыным. Мин эчемнән генә каршы булсам да, авыз ачып сүз әйтә алмадым.

Сүзне кыска тотып, шуны әйтәм: Әлфия белән безнең арада мәхәббәт уты кабынды. Ул кыз бик чая, яшь кенә булса да, шактый үткен булып чыкты - минем йөрәкне әсир итте дә куйды бит! Хатыныма сиздермәскә тырышып йөрсәм дә, ул барысын да аңлап-күреп торган икән. Көннәрнең берендә, балаларны алып, әйберләрен җыйнап, Азнакайга күченеп китеп бармасынмы?..

- Фатирны калдырам, ләкин мин сездән үч алачакмын әле, - дигән сүзләре әле дә колакта шаулап тора.

Без Әлфия белән ярты ел да яши алмадык. Ул икенче бер иргә гашыйк булды һәм аны гаиләсеннән аерып, башка бер шәһәргә чыгып киттеләр.

Ә мин ни кылырга, гарьлегемнән кайсы тишеккә башымны тыгарга белмичә, япа-ялгызым торып калдым. Балаларым юк, хатын юк, инде сөяркә дә эзен суытты...

Шулай да, бар көчемне җыеп, тәвәккәлләп, Азнакайга чыгып киттем. Хатынымның интернат-мәктәптә эшләве хакында хәбәрдар идем, туры шунда бардым. Тик бу очрашу-сөйләшү минем йөрәккә хәнҗәр булып кадалды.

Хатынымда үч алу теләге шулкадәр көчле булган ки, ул Азнакайга килгәч тә теге ахирәте аша Әлфиянең әти-әнисе яшәгән авылны белешә. Башта ул барысын да сөйләп бирергә, ата-анага кызларының чын йөзен ачып салырга ниятли, ләкин тора-бара тагын да мәкерлерәк план кора: ничек тә Әлфиянең әти-әнисенең тормышын җимерергә һәм көндәшеннән шулай үч алырга!

Ничек итсә итеп, хатын Әлфиянең ата-анасы яшәгән йортка барып керә. Үзен социаль хезмәткәр дип таныштыра. Әлфиянең әти-әнисе белән бик тиз уртак тел таба. Тегеләре исә хатын белән якын туганнардай сөйләшәләр, бик якын итәләр. Инде чәче чаларган, өлкәнәеп барган әтисен бик тиз үзенә каратып куя. Аның һәр сүзен тыңларга, һәр теләген үтәргә риза булган ата кеше бар җыйган акчасын үз куллары белән чыгарып сала. Фатир алырга акча җитми, дип алдаган була хатын.

Ярый, монысына әле күз дә йомып калырга була. Хатынның чираттагы “этлеге” - Әлфиянең бертуган абыйсының гаиләсен таркату була. Ике балалы ирне үзенә каратып, хатыныннан аера. Ирне үзе белән Азнакайга алып китә. Законлы рәвештә аерылып беткәч кенә, кара тавыш чыгарган булып, ул ирне өеннән куып чыгара. Сеңлегез дә шул ук хәлне майтарды, янәсе.

Мин генә бу вакыйгалар хакында ишеткәч югалып калдым. Хатыным, бәлки, гафу итәр, бергә бәхетле булырбыз, дигән хыялым да онытылды.

Нишләргә соң мина: хатынымнан гафу сораргамы, әллә инде барысына да кул селтәп, яңа тормыш башларгамы? Алай дисәң, кемгә кирәк бүген баласына алимент түләүче, аз хезмәт хакына яшәүче ир? Җиде юл чатында калгандай хис итәм үземне.

**Г. ӘХМӘДУЛЛИН.**

# Ходай үзе юлларыбызны шулай итеп аергандыр?!.



Җирән чәчле, зәңгәр күзле кызга гашыйк булдым мин. Ул чакта клублар юк, кич утырулар, аулак өйләр генә иде. Менә шул аулак өйләрнең берсендә күрдем мин аны. Күрдем дә, үлдем, дип менә шундый гашыйк булу турында әйтәләрдер, мөгаен. Үзебезнең авыл кызы түгел, күрше керәшен авылыннан. Сорашып, исеменең Таисия икәнен белдем.

Ул кичне кыздан күземне дә алмадым. Үзе дә сиздe булса кирәк, яныма килеп утырды. Берберебезне сүзсез аңлап, дуслашып йөри башладык. Чибәрлеге өстенә, кыз бик уңган, булган да икән. Мин моны аларның өйләренә кергәч белдем. Әти-әнисе каядыр киткәч, үзләренә чакырган иде.

Егет булсам да, мин аңа кагылмадым, яратуым ихластан иде. Озакламый кыз кавышу турында сүз чыгара башлады. Мин бераз шүрләп калдым: минекеләр дә, аларныкылар да безнең кавышуга риза булмаячаклар. “Ә син мине урлап кит”, - диде Таисия. Шулай килештек, әмма кайчан урлыйсымны кызга анык кына әйтмәдем.

Ярар, тәвәккәлләп, урлыйсы көнне, дөресрәге, төнне сайладым. Егетләр белән сөйләшеп, бик шәп атны җигеп, кыз өенең каршысына килеп бастык. Хәзер кызны өеннән чыгарырга кирәк бит инде. Күрешәсе булганда, гадәттә, мин аларның капкаларын каты итеп кага идем. Бу юлы да шулай эшләдем. Хәзер кызның чыкканын көтәргә калды.

Өйдән берәү чыкты. Йөзен күрерлек түгел, дөресрәге, алай текәлеп карап та тормадым инде. Егетләргә ым кактым. Алар кызның өстенә киндер тукыма капладылар да, арбага салып, атны бар көченә куалый башладылар.

Ике авыл арасы әллә ни ерак түгел. Тиз арада кайтып җиттек. Әти-әни дә бу турыда белми иде әле. Төн булуга карамастан, өйгә килеп кердек. Өйдәгеләр уянды. “Әни, мин өйләнәм”, - дидем шундук. Киленне йомшак мендәргә бастырып каршы алырга кирәклеген беләм идем, үзем ята торган мендәрне аяк астына салдым да, кызның өстендәге җәймәне ачтым.

Ни күрим: каршымда кап-кара күзле, чемкара чәчле кыз басып тора. Таисия кайда, дип кычкырып салуымны үзем дә сизмичә калдым. Таисиянең дус кызы Зина иде бу. Озак кайтмагач, әтисе эзләп килгән дип уйлап, иң беренче ул йөгереп чыккан икән.

Я Ходаем, нишләргә?! Нәрсә кылырга?! Әни аны-моны сизми. Әти генә әллә ничек карап тора.

Кыз да аптыраган кебек. Мин аны җитәкләп алдым да, өйнең ал бүлмәсенә алып чыгып киттем. Шунда гына Зина телгә килде:

- Гафурҗан, куып җибәрсәң дә мин өйгә кайтмыйм. Үлүем мең өлеш артык. Урланган кыз икәнемне белгәч, әти барыбер бәреп үтерәчәк. Хәзер бөтен авылга даным тарала инде, хурлык бит...

- Ник алайса башта ук кем икәнеңне әйтмәдең?

- Миннән сорап торучы булдымы соң? Авызымны томаладың бит, сүз әйтергә дә ирек бирмәдең.

- Нишлибез инде хәзер?

- Гафурҗан, өйләнешкән булыйк та, яшәп китә алмасак, аерылып китәрмен. Шулай иткәндә икебезгә дә тигез өлеш чыгачак. Адәм мәсхәрәсенә калдырма, Гафурҗан.

podpiska.ru

Нишлим инде?! Ярар, язмыш шулайдыр инде, дип, Зина белән яши башладык. Яши алмасак, аерылып китәрмен, дигән хатыннан башка андый сүз чыкмады. Үзем дә кабатлап искәртергә кыймадым.

Хәер, кайчан китәсең инде син, дип сорый алмыйм бит. Әти-әни белән бик тиз уртак тел тапты, килешеп яшәделәр. Башка милләт кызы булгач, үз итә алмаслар, дигән идем. Кая ул?! Үз кызлары кебек якын күрделәр Зинаны. Дөресрәге, һәркемгә яраклаша, һәркем белән уртак тел таба белә иде ул.

Илдә үзгәртеп корулар башлангач, читкә чыгып киттек. Балаларыбыз туды. Мин хатынымны яратмадым. Шулай да, аның яратуын тоеп, аның хисләрен хөрмәтләп яшәдем. Бик акыллы, зирәк хатын була белде. Кычкырырга, җикеренергә теләгем булган чакларда да тынычландыра белә иде. Тормышта үз урынымны табып, дәрәҗәле урыннарда эшли алуымны да хатынымның үтә сабыр булуыннан, аңлап, һәрчак юл куеп яшәвеннән күрәм. Соңга калып кайтсам да, кайтмыйча калсам да теңкәмә тимәде, урынлы-урынсыз сораулары белән ачуымны кабартмады.

Тик йөрәк... Йөрәгем гомер бакый җирән чәчле Таисиямне яратып, сагынып яшәде. Ә ул... Ул күптән салкын җир куенында. Гомере кыска булды. Бәлки, барыбер бергә озак яши алмыйсыз дип, Ходай үзе безнең юлларны шулай итеп аергандыр?!.

**Г. ИСМӘГЫЙЛЕВ.**

## Белгечләр фикере

Тормыш авырлыкларында буталган, бөтен дөньядан гайрәте чиккән һәм алга таба ничек яшәргә дип аптырап йөрүчеләргә киңәшләр:

* Беркайчан да ашыкма, бигрәк тә ахмаклык кылырга. Кирәкмәгән эшкә кысылма. Намусың чиста булмау йокыңны качырыр, башыңны авырттырыр.

* Артык дулкынланган, ачу килгән халәттә бернинди карар да кабул итмә, чөнки болай кылган гамәлләр дөрес булмый.

* Дәшми калырга тырыш, беркайчан да бәхәсләшмә, боз кебек салкын калырга өйрән. Шуны онытма: артык хислелек - тәмугка турыдан-туры юл ул.

* Яратырга лаеклы булган кешеләрне генә һәм үзеңне яратучыларны гына ярат. Аларга карата назлы, җылы мөнәсәбәттә бул, әмма чама хисе турында да онытма.

* Ачуыңны китергән кешеләр белән аралашма. Кайвакыт ярты гомер кирәкмәгән танышлар арасында кайнап үтә.

* Сабыр булырга, тыныч кына көтәргә өйрән. Аллаһы Тәгалә турында уйла, Аның белән сөйләш.

* Табигатькә ешрак чык, ул сиңа чиста көч, тынычлык бирер. Табигатькә беркайчан да зыян салма, чөнки ул - тере организм.

* Физик күнегүләр нервыларны ныгыту өчен менә дигән чара. Тирләүдән түгел, ә бер урында утырып “тамыр җибәрүдән” курык.

* Йөрәк борчый башлаган икән, димәк, психик энергия беткән дигән сүз. Кычкырып шигырь укы, җырла һәм тавышың тирбәнеше сиңа көч кертер.

* Сагышлы, күңелсез җыр тыңлама.

* Бозык, әхлаксыз хатыннар яисә ирләр белән чуалма, чөнки алар тормыштан гайрәт чигү хисен арттыра гына.

* Якын кешең хыянәт иткән икән - кичермә, аның белән араңны мәңгегә өз. Юкса, ялган, хыянәт йөрәгеңне туктаусыз кимереп торыр һәм нервыларыңны тәмам бетерер.



## Күңел төшү кебек хисләрне оныт!

* Бирәүдән дә бурычка зур суммада акча алып торма, бигрәк тә процентлар белән. Төшенкелеккә бирелүгә беренче адым бу.

* Яхшы кешеләргә ярдәм ит. Әмма ышанычыңны яулап, беркатлыгыңнан файдаланырга теләүчеләрне танырга өйрән.

* Мәхәббәттә бәхетең юкмы? Бер дә борчылма, бәлки бу яхшыгадыр. Теләсә кем белән йөргәнче, үзең генә калу әйбәтрәк. Ышан һәм көт: мәхәббәт сиңа алдагы тормышыңда килер.

* Дарулар белән мавыкма. Үләннәр, яшелчәләр, җиләк-җимеш белән дәвалан. Ходай Тәгалә эш сөючеләргә, изге гамәлләр кылучыларга сәламәтлек һәм озын гомер бирә.

* Мунчага ешрак йөрергә тырыш, әмма анда сыра һәм аракы кулланма.

* Эштә бирәү белән дә низагка кермә, буш сөйләшүләрдә катнашма.

* Курку, күңел төшү кебек хисләрне оныт. Бу эштә сиңа камиллеккә омтылу ярдәмгә килер. Уй-фикерләреңне яхшырт, тышкы кыяфәтеңне рәткә китер.

podpiska.pochta.ru

# Барсаң табып бар, егетне таныып бар...

Баян белән ике ел буена йөреп, булачак туй көнен билгеләгәч, Гөлзадә... икенче егеткә тормышка чыкты. Туй алдыннан гына Баянга чыкмаска уйлаганын да аның үзенә түгел, ә кеше артыннан гына җиткерде. Баян бу хәбәрне ничек кабул иткәндер, анысы Гөлзадәгә әллә ни мөһим түгел иде. Бу вакытта аның бар уе үз язмышын авыл егете белән түгел, ә шәһәр егете Фәдис белән бәйләү иде.

Баян да начар егет түгел, шулай да аның кендек җебе һаман шул тиресле авылга бәреккәнен ошатмады Гөлзадә. Өйләнешергә сүз куешкач та егет - үз ягына, кыз үз ягына тарта башлады. Гөлзадә шәһәргә чыгып китү теләге белән янды, ә Баянның олыгайган әти-әнисен ташлыйсы килмәде. Баянны бу яктан җиңә алмаячагын аңлаган Гөлзадә аңа алмашка бик тиз егет тапты. Туй кирәк-ярагы алырга шәһәргә барган җиреннән базарда сату-алу иткән Фәдис белән танышты. Туй онытылды. Беренче көнне үк Гөлзадә Фәдистә куна калды. Егетнең берүзенә ике бүлмәле фатирлы булуы барысын да бер мизгелдә хәл итте. Фәдискә дә бу чая, чибәр авыл кызы ошады булса кирәк, тиз арада бергә яши башларга тәкъдим ясады. Әлбәттә, Гөлзадә аңа Баян турында, тормышка чыгарга исәбе булуы турында ачылмады. Үткән эшкә салават, янәсе. Баянның үзен гаепле санады. Ризалашсын иде авылдан китәргә, янәсе. Шулай, булачак ире хакында берни дә диярлек белмичә, Гөлзадә тиз арада тормышка чыгып куйды. Барсаң табып бар, егетне таныып бар да бит...

Туй-мазар дип мәшәкатьләнмәделәр. Фәдиснең туйга чакырырлык әллә ни туганнары да юк икән. Авылга кайтып никах укыттылар да бергә яши дә башладылар. Гөлзадәнең ата-анасы башта, белмәгән-күрмәгән кешегә ничек фатиханы бирик, Баянның ата-анасыннан да



оят, дип карасалар да, кызларының теләгенә каршы бара алмадылар. Авылча әйткәндә, суга дип киткән кыз кияү алып кайткан, кебегрәк булды Гөлзадәнең тормышка чыгуы.

Үзләренә күрә Гөлзадә белән Фәдис матур гына яшәп киттеләр. Базарда кеше товарын сатып торган Фәдис Гөлзадәне үз янына эшкә алды. Кеше белән чатнатып сөйләшә, ышанычка керә белгән Гөлзадә сату эшенә тиз өйрәнеп китте һәм гаилә бюджетына ярыйсы гына өлеш кертә башлады. Бераз гына акча туплагач, икәүләп җиң сызганып фатирда ремонт ясап ташладылар. Шәһәрдә яшәү генә түгел, үз фатирында яшәү хыялы бик тиз тормышка ашуына әле һаман ышанып бетә алмаган Гөлзадә иренә яхшы хатын булырга тырышты. Кемгә шулай җиңел генә эләгә әле ул ике бүлмәле фатир?! Ярый әле аңа Фәдискә очрады!

Гөлзадә ире өчен татлы телен, ачык йөзен кызганмады. Фәдис тә язмышыннан канәгать иде. Матур башланган тормышларының күркәм дәвамы булып, бераздан дөньяга уллары туды. Нәкъ әтиседәй кап-кара малайга Рәдис дип исем куштылар. Гөлзадәнең бәхете бар яктан да түгәрәкләнде.

Бер кичне Гөлзадә иренең эштән кайтуын көтә-көтә көтек булды. Рәдисны күтәреп, тәрәзә янында да басып торды, балконга да чыгып керде. Бераздан улын киендерде дә, караңгы төшүгә карамастан, коляскасын этеп, ирен каршыларга автобус тукталышына китте. Ничә тапкыр шылтыратса да, Фәдис, ни сәбәпледер телефонын алмады. Ни уйларга да белмәгән хатын ире белән бергә эшләгән хезмәттәшләренең берсенә шылтыратты. Күрше бүлектә товар саткан Сәхибә телефонны тиз алды. Фәдиснең кайдалыгын белмисеңме, дип сорагач, Сәхибә, беләм, әлбәттә, дип Гөлзадәне торган саен ныграк аптыраштa калдырды: “Сиңа хәбәр итмәделәрмени? Аны бит бүген хастаханәгә алып киттеләр!”

Көтелмәгән бу яңалык Гөлзадәне аягыннан ега язды. Кайсы хастаханәгә, ни булган Фәдис белән - бу сорауларга Сәхибә бары тик: “Белмим, мин башкача берни дә белмим”, - дип кенә кабатлады. Сәхибә нидер белә, тик яшерә сыман тоелды.

Гөлзадә өенә кайтты да шәһәрнең барлык хастаханәләренә шылтыратып, Фәдисне эзли башлады. Бераздан Фәдис табылды. Ирен тапканга ни сөенергә, ни көенергә белмәде. Ашыгыч ярдәм машинасы үз чире тотып чирләгән Фәдисне эшләгән җиреннән юләрләр йортына алып киткән иде... Дежур табиб Гөлзадәнең кемлеген сорагач: “Әлегә берни дә әйтә алмыйм. Авыру тикшерү үтәргә тиеш. Телефоннан бу хакта сөйләшеп булмый”, - диде дә трубканы куйды.

Аяктан егарлык бу яңалыктан ушлары китеп, Гөлзадә телефонны учында кыскан килеш күпме басып торыр иде, улының елап җибәрүе генә аны аңына-ушына китерде. Әйтерсең лә бала да атасы белән нидер булуын аңлады - ул бу төнне бертуктамый елап чыкты. Черем дә

podpiska.pochta.ru

итмәгән Гөлзадә таң ату белән баласын күтәреп Фәдис яткан хастаханәгә китте. Табиб кичәге сүзләрне кабатлады: "Әлегә диагнозы билгесез. Ирегез тикшерү стадиясендә. Шулай да аңа озак вакыт дәвалану кирәк булачагы ачык".

Табиб рөхсәте белән Гөлзадә Фәдис янына керде һәм артына чак авып китмәде. Кичә генә өйдән үз акылында, үз аягы белән чыгып киткән ире караватта бәйле килеш ята иде: авыруның авызыннан селәгәе ага, акылсыз күзләре, акаеп, түшәмгә текәлгән. Фәдис үз янына кешеләр кергәнен күрде, тик... хатынын танымады. Гөлзадәнең: "Акыллым, бу мин, мин бит бу", - дип өзгәләнүе дә җавапсыз калды.

Фәдис яныннан чыккач, табиб Гөлзадәгә авыру хакында күп кенә сораулар бирде: "Ирегез күптән авырыймы? Приступлары еш кабатланамы?" Авырый? Приступлары?.. "Мин бу хакта беренче ишетәм", - Гөлзадәнең бу җавабына табиб ышанмагандай тоелды. Үз күзләре күргәнгә, колаклары ишеткәнгә ышанырга да теләмичә, Гөлзадә өенә чак кайтып ауды.

Шунда гына Гөлзадә берни белмәгән кешегә тормышка чыгып куюының зур ялгыш икәнлеген аңлый башлады. Бер минутлык ялгыш гомерлек кайгы китерә ала дип юкка әйтмәгәннәр. Ике бүлмәле фатир күргәч тә күзе яна башлады шул. Дөресен генә әйткәндә, ул Фәдискә түгел, ә аның фатирына тормышка чыкты. Фатир иясе кем - аңа барыбер иде. Фәдиснең үзе турында әз сөйләве нидер яшерүе булдымы? Хәер, Гөлзадә үзе ныклап кызыксындымы соң? Күрше-күлән белән артык аралашмасалар да, аларның сынаулы карашларын күрми калмады шул. Фәдис белән икесен очратканда аларның карашында аптырауга якын гаҗәпсенү бар иде бит! Янәсе, нишли бу кыз Фәдис янында?!

Хастаханәдән кайтып бераз ушына килү белән, хатын күршеләренең ишеген шакыды. Олы гына яшьтәге ханым аның күзләрен ачты. Фәдиснең әнисендә дә, абыйсында да әнә шул чир булган. Икесе дә үзләренә кул салган: берсе - асылынып, берсе йокы даруы эчеп үлгән. Бераз сәерлеге сизелсә дә, Фәдис моңа хәтле сәламәт саналган. Күршесенең юләрләр йортына эләгүен ишеткәч, ханым, Гөлзадәгә һәм кечкенә Рәдискә кызганулы караш ташлап, баш чайкады: "Их, балалар!"

Ишеткәннәреннән телсез-өнсез калган Гөлзадә үзе дә чак акылын югалтмады. Түгәрәк дип санаган бәхете бер минутта челпәрәмә килде! Газизенә нинди хаста килсә дә авыр, ә мондый чир авыру өчен дә, аның якыннары өчен дә зур бәхетсезлек! Гөлзадәнең якты көне кара төнгә әйләнде. Терелерме Фәдис? Өмет бармы? Тагын да чирләмәсме? Тик табиблар Гөлзадәнең бу сорауларына җавап бирә алмады. Яшь ананы иң куркытканы - әтисенең чире улына күчмәсме? Бу сорау да җавапсыз калды.

Улын күрше әбидә калдырып, Гөлзадә хастаханә юлын таптый башлады. Тик ак халатлы фәрештәләр Гөлзадәне артык өметләндерә генә алмады: "Нәсел чире... Вакытлыча гына ремиссия булуы мөмкин..." Фәдиснең хәле бер яхшырган кебек булды, бер начарланды. Бер килүендә ире хатынын таныды һәм үзен өйгә алып кайтырга ялварды. Хатыны икенче килүгә ул аны тагын танымады.

Ул хастаханәгә керүгә бер ай, ике ай үтте... Өйдә күптән акча бетте. Гөлзадә ярдәм сорап әти-әнисенә шылтыратты. Әнисе аны әлегә үзләренә кайтып яшәргә күндерде.

Көзге көннең караңгы бер кичендә Гөлзадә, баласын күтәреп, авылга кайтып төште.

Кайтып сыеныр кешеләрең булуы, әлбәттә, зур бәхет. Тик Гөлзадә әти-әнисенең бусагасына бәхетсезлектән кайтып егылды шул. Әти-әнисе, үзең гаепле, теге чакта безне тыңламадың, дип, кызларының йөрәк ярасына тоз өстәмәделәр. Ятныкы яннан үтәр, үзеңнеке үзәктән үтәр шул. Бала кайгысын үз кайгылары итеп кабул иттеләр. Бәлки, кияү терелеп тә китәр, кем белә, дип, Гөлзадәнең сынган күңелен өметләндерергә тырыштылар. Тик Гөлзадә генә моңа ышанмый иде инде. Фәдистән бигрәк, йөрәктә улы өчен гомерлек курку йөртү... Моннан да зуррак газап бармы икән ана өчен?! Чатнады Гөлзадәнең бәллүр бәхеткәйләре!.. Ай бирде, кояш күпсенде. Әллә туй алдыннан качкан өчен Баянның рәнҗеше төштеме икән? Гөлзадәнең йөрәген яндырып, хатыны белән көн дә тәрәзә каршыннан култыклашып үтәләр. Хатыны да әллә кем түгел. Гөлзадәдән ике яшькә кечерәк, почык борынлы бер нәрсә. Баянга чыккач, ничек матурланып киткән! Өйләнешүләренә бер ел да үтмәгән, өй салырга йөриләр.

Үзенең җимерелгән тормышын уйлап, Гөлзадәнең күңелен үкенеч утлары ялмады. Баянга чыкса, бар да башкача булыр иде!.. Тик Баян гына аның хакында, ярый әле шуңа өйләнмәдем дип уйлый булыр. Яраттымы аны Гөлзадә? Әллә Фәдисне ме? Юк шул, Фәдисне түгел, ә бары тик аның фатирын яратты Гөлзадә. Менә инде Гөлзадәнең фатиры да бар, тик куанычы гына юк!

Мәхәббәтсез гаилә - тамырсыз агач икәнен дә белә иде югыйсә. Яратса да, үзен генә сөя, ахры, Гөлзадә. Шулай булмаса, үзе белән язмышын бәйләргә теләгән Баянга аягын сөртмәс иде. Бик акыллы исәп белән корган иде дә оясын, тик исәп-хисабы бик дөрес булып чыкмады. Кайдадыр ялгышты Гөлзадә.

Ялгыш кабул ителгән карар ялгыш атылып киткән мылтык ядрәсенә тиң димәсләр иде. Кичерүен сорарга иде Баяннан. Бала хакына... Ачу рәнҗеш тотмасын иде. Бер күреп сөйләшергә иде Баян белән!

Бераздан Гөлзадәнең теләге кабул булды. Шәһәргә барырга чыккан Гөлзадәне Баян олы юлга хәтле машинасында утыртып килде. Телгә нинди оста булып та, Гөлзадә бу юлы ничек сүз башларга да белмәде. Машинадан төшәр алдыннан гына, карашын да күтәрмичә, ишетелер-ишетелмәс, "Кичер мине", дип куйды. Баян аның бәхетсезлеге хакында ишеткән иде инде. Шунадырмы, сүз озайтмады. "Бәхетле бул, Гөлзадә", - дип кенә җаваплады да район үзәгенә бала табарга киткән хатыны янына ашыкты. Ә Гөлзадәне язмышы ялгышлардан үзе төзегән кискен борылышлы, катлаулы, билгесез юл белән еракка алып китте.

**Физәлия ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВА.**

podpiska.pochta.ru

# Язмышның төсе нинди?



Мин - ирекле рәссам. Мин сәер кешедер, чөнки күзне сагынып көтеп алам. Күзнең төсе сары дисәләр дә, минем өчен ул - яшел. Агачлар гел ямь-яшел утырадыр кебек миңа. Өй эчендә ел дәвамы күз хакимлек итә.

...Хәер, төсләр гел үзгәреп тора. Күз кем өчендер сары, кем өчендер - кара, кемгәдер - кызыл, кемгәдер - көрән. Төсләр гел уйнап тора. Язмыш кебек. Язмышның төсе нинди? Мәхәббәтнең төсен әйтергә кем батырчылык итә? Нәфрәт нинди төстә? Балачак төсе нинди? Дуслык төсен миңа аңлатыгызчы, бик рәхәтләнеп тыңлыйм. Сорауларыма җавап таба алмаганга, ирекле рәссам булып яшәргә уйладым. Чираттагы кыйссамны язам - сызам, язам - сызам, утлы чукмар - гөрзи белән башка орсалар да, ачык төсле рәсем тумый, юк, тумый!

...Ике туган карендәш кызлар Галия һәм Алия чыр-чу килеп уйныйлар. Искиткеч ак, сары, кызыл, ал төсләр балкышы - дуслык төсе һәркемне җәлеп итә. Балачак төсе бит! Йөзләреннән бәхетле елмаю китми. Гамьсез балачакка, туктаусыз шаяруларга дәү нокта куелмас, куелыр дип уйлыйсы килми.

...Менә алар инде мәктәп укучылары... Югары уку йорты шәкертләре... Шаккаткыч төсләр вальс уйный. Сокланырлык зәңгәр, яшел, сары төсләр... Кызлар хәзер дә көләч. Алар хәзер дә бик бәхетле. Баш-аяклары белән укуга чумган кызлар сирәк күрешәләр. Телефоннан хәл-әхвәл сорашыла да бетте-китте. Аралар үзләреннән үзләре суынды - ике туган сылтау, аклану-фәлән эзләп маташмады. Фәрештәләрнең иннәренә нинди мәшәкатьләр кунгандыр - кинәт тынды кызлар. Гаҗәеп төсләр сүрелде.

Инде менә сөйгән ярлары белән кавышу мизгелләре дә җиткән икән - тик бер-берсенә ләм-мим. Аталары - бертуган ирләр Шакир белән Закир, әниләре - килендәшләр Рәзифә белән Мәдинә никах, туй турында уртага салып сөйләшәсе итмәде. Ике туган кызга - Алиягә дә, Галиягә дә бер үк көнне баш кодалар юл алды. Һәм иң гаҗәбе - ике кызның да никахлары бер үк көнне, бер үк сәгатьтә икән! Бу хәбәрдән башым эшләми башлады - менә шул мизгелдә минем рәсемемә аклы-каралы төсләр килеп керә. Ни өчен дисәгез, абыйлы-энеле Закир белән Шакир бер-берсенә кунакка - кызларының никах мәҗлесенә бара алмыйлар булып чыга бит әле! Туган хакы - Тәңре хакы бит! Шул исәптән нәселнәсәп тә аптырауда. Алия никахына барсаң, Галия үпкәли, Галиягә барсаң, Алия рәнҗер кебек...

Кызларның әтиләре эчтән тынды, әниләре дәшмәүне хуп күрде, Алия белән Галия генә анык фикергә килә алмадылар. Никах көнен күчерү турында сүз кузгатылгач, ике як та үпкәләште, хәтта рәнҗеш җиле исеп киткәндәй булды. Ирекле рәссамга бу гамәлне, гауганы нинди төскә буяса да килешә дип уйламагыз тагын! Сез, галиҗанәпләр, минем урында булсагыз, ни диярсез икән? Бер төскә генә сыямы бер кочак хис?! Бик шикләнәм. Үпкәләү, рәнҗүне ачык төсләр белән буяудан мәгънә юк - бөгырең өзелеп төшә ләбаса!

...Гөрләп никахлар үтте. Таң калырлык апак күлмәкләр, алтын балдаклар киелде, дөнья ап-ак иде. Шул аклыкның бер кырые гына каралган кебек тоелды миңа - ирекле рәссамга.

podpiska.pochta.ru

Туганнар хакы хакланмады бит! Минем төсләр куертып теңкәм корды. Башкаларның елмаюы астында рәнҗүле никахны төсе сизелмәслек итеп куерттым. Үзем ни гәүдәләндердем, шул ошады, чөнки еламсыраган төскә урын калмады. Әз генә җиңел сулап куйдым. Бөтен вөҗүдемне сары кояш нуры назлады. Ни дисәң дә туй бит!

Туйлар үтте - ал да гөл. Ике яшь парның - якын кардәшнең бәхет сибелгән язмыш рәсемен элеп куйдым. Эшем тәмамланды. Вәгазь вә гыйбрәтле хәлләр сөйләүче түгел, гаять матур декорацияләр ясаучы рәссам гына булып калдым. Аллага шөкер...

Төсләр кабат куерды. Юлларда таймас өчен ат тоягына дага кадаклап була, кешенекенә - юк. Таяну ноктасы булмаганга ул абына. Яшь парларның берсе - Алия аерылып та өлгергән. Яралгы рәвешендә таркалган никахны шәмәхә төсле иттем. Рәнҗүле никах тиз таркалды. Әйтәм бит, төсләр һәрвакыт үзгәрештә. Җылы җәй аенда - искиткеч гүзәл төсләр ут булып янганда, күкне кара болыт каплый. Җәй төсләрен санап китсәң... Санап бетергесез... Бер төскә генә сыямы үпкәләр, күз яшьләре?! Җәй соры да була икән?! Аерылышкан пар өчен - соры, кавышканнар өчен - ачык төсләр балкышы.

## Шифалы киңәш

### *Каен суы организмны ныгыта*



*Язны без җылы кояш нурларын, җир өстен чистартучы ташкыннарын, сызгырып җырлаучы сыерчыкларын, кар эрү белән калкып чыгучы умырзаяларын күрер өчен сагынып көтеп алабыз.*

*Сәламәтлек өчен файдалы булган каен суын да нәкъ менә табигать кышкы йокыдан уянганда тәмләп карарга була. Унган хуҗалар һәм хуҗабикәләр каен агачының суын гына түгел, бөреләрен дә, яфракларын да хәстәрләп куя. Тик бу эшне агачларга зыян китермичә, сак кына башкарырга кирәк.*

*Медицина максатларында каенның бөреләрен, яфракларын, суын, дегетен һәм күмерен файдаланалар.*

*Бөреләрендә 6 процентка якын эфир мае бар, аның составына бетулен һәм бетуленол, сесквитерпеннар керә. Яфракларында бетулоретин һәм аскорбин кислоталары, сапониннар, эфир мае, гиперозид һәм дуплау матдәләре булуы ачыкланган.*

*Каен суы, шулай ук аның консервланганы да, организмны гомум ныгыту чарасы буларак киң кулланыла. Ул витаминнарга, минераль тозларга, төрле микроэлементларга бай, анда алма кислотасы, шикәр, дуплау матдәләре, хуш исле башка матдәләр бар.*

Сокланырлык икенче пардан - Галия нәни малай алып кайтты. Аларга дигән яңа нигезгә беренче таш та куелды. Кардәш-ыру бергәләп йорт җиткезде. Илһамландыра торган төсләрдән күзләр чагыла.

Никахы таркалган кыз Алия үзенең әниләрендә ялгыз гына бәби үстереп ята. Ире Илнур баланы үзенеке түгел, ди икән. Илнур ерак шәһәргә китеп югалган, хатыны һәм баласы тора торган йортны (Галиянең әти-әнисенең йортын) комарлы уенда оттырып өлгергән. Ата-ана кызны бу ирдән рәсми аерып, бөтенләй чит кеше белән тиз арада язылыштыралар. Сәбәбе - бу йортта бер тиенлек тә хакы булмауны дәлилләү.

Икенче никахта - Алия белән Геннадий никахында - кызның әти-әнисе кул күтәреп дога кылды, егетнең әти-әнисе артка карап чукынып утырды. Кардәш ыру икенче никахны белмичә дә калды, ахырдан - тагын рәнҗеш. Бу никахның төсен башта мин караламага гына ясап карадым. Гадәттәгедән дә куерак килеп чыкты. Бутый торгач, кара буяу боткасына әверелде дә куйды - ирекле рәссам үзеннән-үзе җирәнде. Ягъни үз-үземнән җирәндем...

Я, Рабби... Янәдән шул парның зур сынау үтәсе бардыр - юл фаҗигасына очрыйсылары бардыр, теге ике көнлек никах таркаладыр, кыз гарип булып каладыр. Геннадий шактый мал-мөлкәтне әрәм-шәрәм итеп бетерәдер... Бу кайгыларны күтәрә алмыйча Алиянең әнисе үләдер... Тагын ике елдан әтисе дә кызы белән оныгын ташлап китәдер...

Мәет күмәргә ике туган кыз Галия килә алмый, чөнки тиздән икенче бәбине алып кайтырга җыена. Бер кадак бәхете булмаган Алия кардәш кыз туганыннан көнләшә, рәнҗи. Туганы Галиянең сөйгән яры янында, йорты бар, бәбиләре үсә, икенчегә авырлы, әти-әнисе исән...

Язмышка коршау кидерә алмыйсың, язмышны алдан гөманлый алмыйсың. Язмыш кырыгалдар түгел, ничек язылган, ул сиңа шуны күзлексез кычкырып укый... А-а-а-ай!

... Ирекле рәссам бик кыстаса гына килә торган төсләр бар - җирән кара төс, көрән кызгылт сары төс. Бу төсләр шулхәтле куркыныч ки, хәтта минем кебек ирекле рәссамны да куркыта алалар.


Галия икенче бәбине алып кайта. Дөньядагы иң бәхетле пар булып яшиләр. Матәм төсендәге яңгыр яуганчы тормыш шулай дәвам итә. Көннәрдән беркөнне, Галия һәм ике бала самолетта янып үлгәнче.

Кара, сурәтләп тә булмый торган караләҗым төсләрне гаскәр туплап та куып җибәреп булмады. Икенче никах та җиде елдан таркалды. Күкләрдә шулай язылганмы, адәм үзе язамы? Мин бүген хәтта ирекле рәссам да түгел, сүзсез бер адәм кисәге. Бу хәл мине мәңге сүнмәс утларга салды. Минем якыннарым, чөнки...

**Каләмгөл.**

podpiska.pochta.ru

# Күрәчәктән качып буламы?



Разыяның язмышындагы фаҗигане аңлау өчен аның тормышын баштан ук сөйләү кирәк. Разыя сигезенче сыйныфка кадәр яхшы гына укып, тәртипле генә йөри. Мәктәпне тәмамлагач, алга таба укырга бик теләсә дә, әнисе каршы төшкәч, эшкә керә. Анасын аңлап була: балаларның әтиләре, берсеннән-берсе кечкенә дүрт сабыен калдырып үлеп китә, тормыш итү авыр, ананың хезмәт хакы аз, сабыйларына ятимлек өчен бирелгән пенсия акчасы ашарларына да җитми.

Әниләре һәм апалары Разыя эштә вакытта өйдә үзләре генә калган балалар шырпы белән уйнап, ут чыгаралар. Ярый әле өсләреннән бикләп калдырылган сабыйларны урамнан узып баручы ир, күреп алып, коткарып кала. Ә ир үзе, өстенә янган түшәм ишелеп төшеп, ут эчендә һәлак була. Үз гомере хисабына сабыйларны коткарган ирнең күрше авылның яңа гына өйләнгән агрономы - Фердинанд икәнлеге икенче көнне иртән генә ачыклана.

Бу фаҗигадән соң ирнең җиде айлык көмәнле хатыны Әлфинур көне-төне елый, иртән зиратка китеп югала, аннан аны кичкә көчхәл белән алып кайталар. Бер атна үткәч, Әлфинурда төрле сәерлекләр күренә башлый. Ул табын янында тәлинкәсенә карап утырган җиреннән кинәт көлеп җибәрә. Элек Фердинанд утыра торган буш урынга карап, аның белән сөйләшә башлый. Ике көн шулай сәерләнеп йөргән хатынны өченче көнне сырхауханәгә алып китәләр. Ләкин Әлфинур өч сәгатьтән үлә, сигез айлык баласы да туарга өлгерми. Табиблар хатынның баш миенә кан сауган дигән диагноз куялар.

Фердинанд белән Әлфинурның әти-әнисе Разыялар гаиләсе белән гел очрашып тора: юлда, эшләре дә бер урында. Хәсрәттән кара көйгән, җилдә селкенеп торыр хәлдә ябыккан ата-аналарны күреп яшәү Разыя өчен тәмуг газабына әйләнә. Гәрчә, алар кызга бер генә авыр сүз әйтмәсәләр дә.

Бервакыт Разыя Фердинандның әнисе Раушания апаның ферма тәрәзәсеннән гел бер ноктага текәлеп торуына игътибар итә (Разыя белән Раушания апа бер үк фермада сыер савалар). Әллә ничә көннәр һаман шул юнәлештә карап катып тора ул. Раушания апа чыгып киткәч, Разыя тәрәзә янына килеп, тышка күз сала, берни дә юк ич дип уйлый ул еракка сузылган кырга, урманга карап һәм кинәт эсселе-суыклы булып китә. Әллә ни ерак та түгел зират күренеп тора, ә анда ап-ак кар өстендә аерым-ачык булып ике кара калкулык ярылып ята. Разыя хәлсезләнеп җиргә чүгә, шабыр тиргә бата. Аның ике энесен, сеңлесен коткарып, үзе кара күмергә әйләнгән Фердинанд абыйсының, шул хәсрәтне күтәрә алмыйча үлгән Әлфинур апасының каберләре бит алар.

Димәк, Раушания апа сәгатьләр буе шуларга карап тора. Разыя күңелендәге газап икеләтә арта. Беркемгә дә әйтеп булмаслык сер җанын баса аның, сулышын кыса...

Янгын чыгасы көнне Разыя эштән соң күрше авылда яшәүче дус кызы янына китә, төш вакытында өенә кайтырга тиеш булса да, кичкә кадәр шунда утыра. Әгәр ул иптәш кызы яныннан ике генә сәгать иртәрәк кайткан булса да, әлеге фаҗига чыкмас иде. Кызыга ул мәктәптән соң институтка кергән иптәш кызына. Ә үзе менә өченче ел инде фермада этләнә. Бер генә көн сөйләшәсе килә аның иптәш кызы белән. Җитмәсә, фаҗигадән соң әнисен алдый: "Мин кибеткә генә киткән идем", - ди. Кибә Разыя, корый, башны бауга тыгаргамы әллә дип тә уйлый. Әнисе аңа шарт куя: "Авылдан бары кияүгә чыгып китә аласың, алайса анда, ирекә чыккач, яшьләр теләсә-нәрсә эшләп йөри диләр".

podpiska.pochta.ru

...Разыяның күрше авылның атаклы исерегенә, эчкәч котыра-котыра сугыша торган Гаязга кияүгә чыкканын ишетеп, авыл халкы шакката. Ә Разыя үзе моңа сөенеп бетә алмый. Ниһаять, ул авылдан китәчәк, бәлки әле бөтенләй башка районга, йөзләрчә чакрым читкә, Гаязның апасы яшәп ята торган җиргә. Эчсен, сугышсын, алып кына китсен!

Башта әйбәт кенә яшәгән гаиләнең тынычлыгы озакка бармый. Разыя инде биредә үзенә дуслар таба, эшкә урнаша, хезмәт сөя торган кызны иптәшләре ярата, Гөлниса исемле апа белән Гаязның түтәсе Наилә бигрәк тә үз итәләр аны. Ике ел матур уза, Разыя күршесе, хезмәттәше Гөлниса апага туганнарының ни өчен, ничек ут эчендә калуларын, кем коткарганын - барысын да ничек булган, шулай сөйләп бирә. “Язмышың шулайдыр, эшәкелек белән эшләмәгәнсең бит син, Ходай кичерер”, - дип юата фаҗига өчен һаман үзен битәрләгән хатынны Гөлниса апа.

Йөрәк ярасы әкренләп йомыла башлый, әмма Разыя авылына беркайчан да кайтмый. Әнисенә күчтәнәч кенә җибәрә, аны кунакка чакыра. Бер эштән икенчесенә күчеп йөргән ир исә эчә-эчә котыра, әйбер вата, җимерә. Түтәсе Разыяны мөмкин кадәр сакласа да, ир аңа кул күтәрүне чүпкә дә санамый башлый. Разыяның күз төбе күгәргән көе эшкә килүләре инде даими-гадәти хәлгә әверелә. Үзе зарланмагач, җитәкчелек дәшми, нәрсәдер эшли алган булырлар иде, югыйсә. Барыр җире булмаган Разыя һаман шул котырган хайван янына кайта. Наилә түтәсе бер атнага авылга кайтып китә, Разыя аның артыннан әнисенә, туганнарына бик күп күчтәнәч, кием-салым җибәрә. Шуннан Разыя ике көн эшкә килмәгәч, хезмәттәшләре борчылалар, чөнки ул бик каты авырганда да эштән калмый торган була. Өченче көнне телефонга да җавап бирмәгәч, Гөлниса апа аларга керә. Өйдән ләх исерек Гаяз чыга, сораганны да көтеп тормыйча: “Разыя авылга кайтып китте, йөрмә монда”, - ди. Кире чыгып барганда Гөлниса апа бик шикләнеп артына борылып карый һәм Гаязның ниндидер чүпрәкне баскыч астына тибеп кертергә азаплануын күрә. Гөлниса апаны ниндидер шик, борчу баса, тора-тора бу хис шомга әверелә. Ә бит Разыя авылга кайта алмыйм дигән иде, дип исенә төшерә ул.

Ниһаять, Разыя югалганга бишенче көн дигәндә, бер иптәшен ияртеп, Гөлниса апасы күршесенә юнәлә. Ишек шар ачык, өстәл тулы буш шешә, Гаяз идәндә йоклап ята, саркылып кына начар ис сизелә. Гөлниса апа хәзер дә әйтә алмый бу иснең нәрсәне хәтерләткәнен, “авыр, баллы ис” ди. Ике бүлмәне карап чыгалар - берни юк. Гөлниса апа Гаязның ниндидер чүпрәкне баскыч астына тибеп кертүен исенә төшерә. Өстерәп чыгарып, җәеп карасалар, егылып китә язалар: бу - Разыяның эшкә соңгы мәртәбә киеп килгән күлмәге, канга баткан, тишкәләнеп беткән.

Чакыруга килеп җиткән полиция хезмәткәрләре ирне уятып, сораштырып карасалар да, ул аңлаешлы берни әйтә алмый. Тентү вакытында почмакта паласка төрелгән Разыя мәетен табып алалар. Исләнә башлаган, шәп-шәрә гәүдәдә егермедән артык пычак эзе була.

- Үтерсәм соң, үз хатыным бит, - ди Гаяз тикшерүчегә. - Сарайга алып чыктым да, ярты сәгать типкәләдем, һаман үлми, пычак алып чыгып чәнчедем, палас алып чыгып, шунда төрдем, төргәндә нигәдер күлмәген салдырдым. Төнлә урманга илтеп күмәсе идем, теге убырлы карчык керде дә эшне бозып ташлады. Күлмәген чак читкә атып өлгердем, ул чыгып киткәч, баскыч астына тибеп керттем. Ярар, төнлә илтеп күмәрмен дип уйладым, әмма сарайда калдырырга курыктым, теге убырлы карчык кереп, иснәнеп йөрер дә, табар дип. Өйгә алып кереп, караңгы почмакка аттым. Төн җиткәнче ятып ял итим дип уйладым. Кибеткә чыгып, бер ярты алып кердем. Эчеп бетергәнмен, аннан полиция уятты.

Бу вакыйгада, белмим, кемне гаепләргә була? Разыяның үзенме? Бәлки аңа аерылырга кирәк булгандыр? Менә дигән хатынын харап итүче исереккә дә ни әйтеп була?! Маңгайга язылган язмыштан качып булмыйдыр, күрәсең...

**Исемем редакция өчен генә.**

# Бакчага утыртып була



Бүләк ителгән чәчәк бәйләмендәге роза иртәме-соңмы шиңәчәк. Әмма уңган бакчачылар аларны затлы куакка әйләндерә белә. Бу эшне дөрес башкару өчен берничә киңәшкә колак салырга кирәк.

Тамыр җәйдерү өчен консервантлар белән эшкәртелгән Голландия розалары яраклы түгел. Шиңгән яфракларны алып ташларга кирәк, алар тамыр җәйгәндә черүгә китерә. Яшь ботаклары һәм ачылмаган бөреләре булган розалар да бакчага күчереп утыртуга ярамый.

Белгечләр сабакның урта яисә өске өлешен алырга киңәш итә. Аларның һәркайсында өч һәм аннан да күбрәк күз булырга, әмма аның озынлыгы 25 сантиметрдан артмаска тиеш. Астан 45 градуслы почмак ясап кисәләр. Ботакның аскы өлешендәге барлык энәләрне, яфракларны чистартырга кирәк, шуннан соң аны 6 сәгать тирәсе ашламалы суда тотарга. Бер стакан суга бер кашык бал салынган катнашма да яхшы.

Сабакны туфракта да тамырландырырга мөмкин. Моның өчен бер бөресе капланганчы сулы стаканга утыртырга кирәк. Сабакны банка белән каплап куярга.

Көннәр җылыткач, розаны бакчага күчереп утыртырга да мөмкин булачак.

podpiska.pochta.ru

## КИҢӘШЛЕ ЭШ ТАРКАЛМАС!

# Балага файдалы ризык ашатасызмы?



Балага аның дөрес һәм нормаль үсүе өчен мөһим булган бөтен ризыкны да ашатырга кирәк. Ризыкта аксымнар, майлар, углеводлар, витаминнар, су һәм тозларның булуы аеруча әһәмиятле.

Аксымнары йә майлары, яисә углеводлары гына күбрәк булган бертөрле азык ашатсан, бала дөрес үсә алмый. Мәсәлән, әгәр сабыйга күбесенчә ботка, шикәрле камыр ризыклары (печенье, сохари, икмәк, булка) ашатканда, аның авырлыгы арта, ул тазара, бу хәл эти-әниләрне сөендерә. Әмма баланың сәламәтлеге өчен бу зарарлы. Гадәттә андый балалар йомшак тәнле, аз хәрәкәтләнүчән була, психик үсеше ягыннан үз яшьтәшләреннән артта кала, еш авырый. Балаларга боткаларны, яшелчә ашларын, ит, сөт, эремчек, сыр һәм башка сөт продуктлары, йомырка, балык белән әзерләргә кирәк. Сабый организмы өчен атланмай, балык мае, йомырка сарысы бик файдалы. Тик ике яшькә кадәрге балаларга - маргарин, өч яшькә кадәр дуңгыз мае ашатырга ярамый. Бала диетасында үсемлек мае 25 процентган да ким булмаска тиеш.

Әти-әниләр сабыйга еш кына майны күбрәк бирергә тырыша. Бу дөрес түгел. Кирәгеннән артык май ашказаны суты эшләп чыгаруны тоткарлый, ашказанында һәм эчәкләрдә ризыкның үзләштерелүенә, аксымнарның сеңүенә начар тәэсир итә. Ризыкта май күп булса, ашказанында азык алты сәгатькә кадәр тоткарлана, ә нормаль бушану өч-дүрт сәгатьтә була. Майны артык ашаганда баланың аппетиты начарлана, авырлыгы артмый. Балык маен да артык күп эчерергә ярамый. Ике яшькә кадәрге балаларга - ашаганнан соң көненә өч чәй кашыгы, ә олырак яшьтәгеләргә ике-өч десерт кашыгы бирелә.

Балага кальций, фосфор, калий, натрий, тимер, йод, хлор, фтор кебек минераль матдәләр кирәк. Яшелчә, сөт ризыклары, җиләк-җимеш, боткалар минераль матдәләргә бай. Балаларга ашар алдыннан татлы ризыклар бирергә ярамый. Ике яшьтән зуррак сабыйларга ашаганнан соң, аппетиты яхшы булган очракта гына, баллы ризыклар ашатырга мөмкин.

Татлы ризыклар теш өчен дә зарарлы. Бигрәк тә йокларга әзерләнгән балага кәнфит бирү тыела, чөнки шикәр әчегәндә хасил булган кислота төне буе тешне ашый.

Алай гына да түгел, артык шикәр ашказаны асты бизләренең эшчәнлеген киметә, ә олыларда кан тамырлары стенасы һәм йөрәкнең тукталуын боза.

### *Йөрәк белән шаярма!*

*Инфаркт авыруына еш кына кырык биш яшьтән узган ирләр һәм илле яшьтән өлкән хатын-кызлар дучар була. Шуңа күрә аларга дөрес тукланырга, холестерин күләмен тикшертеп, кан басымын даими үлчәп торырга киңәш ителә. Алкогольле эчемлекләрдән, тәмәкедән баш тарту мөһим.*

*Ә инсульт мидәге кан әйләнеше бозылу белән бәйле авырулар арасында үлемгә китерүче иң куркыныч ун авыру рәтендә тора. Аның елдан-ел “яшәрүе” бигрәк тә куркыныч күренеш. Ишемия һәм геморрагик инсульт билгеләре: баш авырту, баш әйләнү, хәлсезлек, укшу һәм косу.*

podpiska.pochta.ru

**Аллаһ юлы - нурлы юл**



*Исем алыштыруны Ислам тыймый. Ләкин шуны онытмаска кирәк, яңа исем уңай мәгънәле, дингә якын булырга тиеш. Чөнки Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Сабый дөньяга аваз салгач, ата-ана аңа матур, мәгънәле исем кушарга тиеш”, - дип әйткән. Исем - нәселнең асылы.*

*Иң хәерле исемнәр: Габдулла, Гәбдрәхим һәм Пәйгамбәрләр исемнәре. Мәсәлән, Мөхәммәд белән Ибраһимны атарга була.*

*Кайвакыт, исем алмаштыру хәерле дә булырга мөмкин. Сөекле пәйгамбәребезнең ике очракта кешеләрнең исемнәрен алыштыруы күренә. Беренчесе, кеше күтәреп йөргән исем аеруча зур мәгънәгә ия булганда. Чөнки, кеше ул исемгә туры килеп бетмәскә мөмкин. Мәсәлән, пәйгамбәребезнең хатыны Зәйнәпнең исеме баштарак Бәрра - “бик изге” мәгънәсендә булган. Пәйгамбәр, аны тыйнаклыкка өндәп, Зәйнәпкә алыштырган. Әмма бу динебездә киңәш рәвешендә килә һәм мәҗбүри таләп булып тормый.*

*Икенче очрак - исемнең мәгънәсе начар булганда. Пәйгамбәребез бер Гасыя (гөнаһлы) исемле хатынга: “Син Җәмилә (матур) исемле буласың”, - дигән. Бер Хөзен (кайгы) исемле ирнең: “Син Сәһел (җиңеллек) буласың”, - дип исемен үзгәрткән.*

# Исем алыштыру кешенең язмышын үзгәртә аламы?

*Килеп туган һәрбер мәсьәләдә без чыганакларга таянып эш итәргә тиешбез. Пәйгамбәребез (с.г.в.) һәм дин галимнәре нәрсә эшләгән? Әйе, Рәсүлебез (с.г.в.) кешеләрнең исемнәрен алыштыра иде.*

*Мәсәлән, татарларда Габдулла исеме киң таралган. Ул Аллаһы Тәгаләнең колы дигән мәгънәдә. Элек ул гарәпләрдә төрле потларның коллары буларак билгеле иде. Рәсүлебез бары тик авыр, мәгънәсе ягыннан матур булмаган исемнәрне алыштырган.*

*Татарлар арасында исем алыштыру модага кереп китте, соңгы вакытта бик күпләр исемнәрен алыштырырга дип мәчеткә килә. Берәүләр бер күрәзәчегә бардык, исемең шундый авыр, ямьсез, бөтен тормышыңны бозарга сәләтле диде, шуның өчен килдек, диләр. Ни генә булмасын, исем алыштыру гына кешенең язмышын тулысынча үзгәртә алмый.*

*Рәсүлебез (с.г.в.) үзе болай ди: “Әгәр исем алыштырып кына язмышлары үзгәрә дип уйласалар, тизрәк тау күчәр иде”, - ди. Пәйгамбәребез хәдис-шәрифләрендә дә әйтә: “Йөрәк турысындагы бер кисәк чиста булса, бөтен тән чиста булыр”. Ягъни, йөрәкне төрле начарлыктан чистартырга кирәк. Хәерсез исемнәр кушудан тыелырга. Әгәр әти-әниләрегез кушкан исем төпле, яхшы мәгънәле икән, аны үзгәртергә кирәкми. Безгә күп очракта, исемнәрен үзгәртү өчен тормышларында кыенлыклар туган, эшләре начар барган кешеләр мөрәҗәгать итә. Араларында күпчелеге 40-45 яшьтәге хатын-кызлар.*

*Әгәр дә ата-ана мәгънәсез исем сайлаган икән, аңлату эшләре алып барырга, башка матур исемнәр тәкъдим итәргә кирәк. Илнар, Динар, Люция, Ленар, Марс кебек исемнәрне кушмау хәерле, алар безгә совет заманыннан килгән. Тәмугка кермәс өчен алардан ераграк торырга киңәш итәм.*

*Гомумән, исем кешенең шәхси хакы, шуңа күрә, ул гомере буе үзе теләмәгән исемне йөртергә тиеш түгел. Теләгән кеше мәгънәсе күркәм булган, милләтенә, халкына туры килгән, күңеленә ятышлы исемне алырга хаклы.*

*“Үлгән кешенең исемен кушарга ярыймы?” - дип тә сорыйлар. Һәркем кайчан да булса вафат була, шуңа күрә моңа игътибар итү кирәкми. Алай гына да түгел, яшь буын үзенең нәсел шәҗәрәсен өйрәнеп, әби-бабайларының исемнәрен өйрәнеп, үз балаларына шул исемнәрне кушсалар, бик күркәм булыр иде.*



**Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН.**

podpiska.pochta.ru